КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 24 декабрь г.Казань № 1211

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 – 2020 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2016 ел, 10 июнь, 395 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 – 2020 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2016 ел, 10 июнь, 395 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 5 июнь, 342 нче, 2017 ел, 12 сентябрь, 650 нче, 2017 ел, 27 ноябрь, 911 нче, 2018 ел, 14 май, 363 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карар исемендә «2016 – 2020» саннарын «2016 – 2021» саннарына алмаштырырга;

1 пунктта «2016 – 2020» саннарын «2016 – 2021» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «2016 – 2020 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасында (алга таба – Программа):

Программа паспортында:

«Программа исеме» юлында «2016 – 2020» саннарын «2016 – 2021» саннарына алмаштырырга;

«Программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары» юлында 2016 – 2020» саннарын «2016 – 2021» саннарына алмаштырырга;

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре | Программаны Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслауның гомуми күләме 1 302 744,5 мең сум тәшкил итә, шул исәптән еллар буенча:<br>2016 ел – 131 029,4 мең сум;<br>2017 ел – 264 939,7 мең сум;<br>2018 ел – 258 309,4 мең сум;<br>2019 ел – 216 608,9 мең сум;<br>2020 ел – 215 811,1 мең сум;<br>2021 ел – 216 046,0 мең сум.<br>Искәрмә: финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле финас елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш»; |

«Еллар буенча бүлеп, Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелгән соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар буенча бүлеп, Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелгән соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашыру 2021 елга түбәндәге күрсәткечләргә ирешүгә мөмкинлек бирәчәк:<br>дәүләт архивлары биналары архив документларын даими саклауны тәэмин итә торган норматив шартларга туры килү дәрәҗәсенә 98,5 процент җитүгә;<br>иминият күчермәләре булган уникаль һәм аеручы кыйммәтле документлар өлеше 91 процентка кадәр артуга;<br>дәүләт архивлары өчен элек алынган документларның гомуми санында түләүле нигездә алынган документлар өлеше 01.01.2016 ел торышына 100 процентка кадәр артуга;<br>Татарстан Республикасының документаль мирасын популярлаштыруга юнәлтелгән чаралар саны елга өч данәгә кадәр артуга;<br>тану һәм тасвирлау таләп ителгән документларның гомуми санында фәнни тасвирланган документлар өлеше 100 процентка кадәр артуга;<br>грант нигезендә тормышка ашырылган проектлар саны елга 31 берәмлеккә кадәр артуга;<br>бер елда үтәлгән соратуларның гомуми күләмендә архивлар тарафыннан билгеләнгән вакытларда үтәлгән соратулар өлеше 99 процентка кадәр артуга; |

| | |
|---|---|
| | Татарстан Республикасында архив эше белән идарә итүнең мәгълүмат-аналитика системасына тоташкан дәүләт һәм муниципаль архивлар өлеше 100 процентка кадәр артуга;<br>электрон документлар әйләнеше системасының шәхси кабинетлары аша документлар тапшыруны гамәлгә ашыручы оешмалар – комплектлау чыганаклары өлеше 100 процентка кадәр артуга;<br>«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре ярдәме белән аудиовизуаль продукциянең мәҗбүри нөсхәләрен электрон кабул итү һәм тикшерү системасының шәхси кабинетлары аша документларын җибәрә торган оешмалар - аудиовизуаль продукциянең мәҗбүри нөсхәсен җитештерүчеләр өлеше 80 процентка кадәр артуга;<br>аудиовизуаль продукциянең мәҗбүри нөсхәсен җитештерүче оешмаларның гомуми санында документларын системаның шәхси кабинетлары аша тапшэыра торганнары өлешен 50 процентка кадәр артуга;<br>цифрлаштырылган һәм индексацияләнгән исемлекләр һәм делолар исемнәре, муниципаль архивларны исәпкә алып, 100 процентка кадәр артуга;<br>саклаunion торган аеруча кыйммәтле берәмлекләрнең гомуми санында цифрлаштырылган аеруча кыйммәтле берәмлекләр өлеше, муниципаль берәмлекләрдә табылганнарын исәпкә алып, 100 процентка кадәр артуга;<br>Архив фондында саклана торган берәмлекләрнең гомуми санында цифрлаштырылган аеруча соратыла торган саклана торган берәмлекләрне 4 процентка кадәр артуга;<br>бабин гомуми санында цифрлаштырылган бабин кинопленка өлеше 50 процентка кадәр артуга;<br>мәгълүматлар саклауның бердәй системасында сакланган цифрлаштырылган контент өлеше 500 процентка кадәр артуга;<br>стипендия алган стипендиатлар санын елына 43 кешегә кадәр арттыру;<br>генеалогия буенча порталны кулланучылар санын елына 500 кадәр арттыру;<br>дәүләт һәм муниципаль архивларда модернизацияләнгән эш урыннары санын 230 берәмлеккә кадәр арттыру;<br>«Электрон уку залы» керүчеләр санын 3500 кешегә |

| | |
|---|---|
| | җиткерү;<br>кулланучыларның күрсәтелгән дәүләт хезмәтләре белән канәгать булуын 90 процентка җиткерү;<br>әзер муляжларны кулланып экспонатлаштыру буенча чаралар санын елына 8гә кадәр арттыру;<br>уку залында бирелергә тиеш бер елдагы делолар саныннан штрих-код делолар санын 100 процентка кадәр арттырырга»; |

Программаның II бүлегендәге 7 пунктның өченче абзацында «2016 – 2020» саннарын «2016 – 2021» саннарына алмаштырырга;

III бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программаны тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү законнарда билгеләнгән тәртиптә бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты акчасын куллануны күздә тота.

Программаны финанслауның гомуми күләме 1 302 744,5 мең сум тәшкил итә:

2016 ел – 131 029,4 мең сум;

2017 ел – 264 939,7 мең сум;

2018 ел – 258 309,4 мең сум;

2019 ел – 216 608,9 мең сум;

2020 ел – 215 811,1 мең сум;

2021 ел – 216 046,0 мең сум.

Программаны тормышка ашыруны ресурслар белән тәэмин итү фараз характерында була һәм тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып ел саен тәгаенләнергә тиеш.»;

Программага кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин